| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.02.2021 Баулы шәһәре № 41

Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибе турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы карар итте:

1. Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре башка түләүле эшне башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә (эш бирүче) алдан хәбәр итү тәртибен расларга.

2. Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнарына Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре башка түләүле эшне башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибе нигезендә эшне оештыруга җаваплы вазыйфаи затны билгеләргә.

3. «Баулы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре башка түләүле эшне башкарырга ниятләү турында хәбәр итү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының 2014 елның 21 октябрендәге 234 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районы Советының
2021 елның 18.02.
41нче номерлы карарына
кушымта

Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре башка түләүле эш башкару турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан хәбәр итү тәртибе (алга таба - Тәртип) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 11нче статьясы 2нче өлеше нигезендә Баулы муниципаль районы территориясендә коррупциягә китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү, Баулы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре (алга таба – муниципаль хезмәткәр) тарафыннан башка түләүле эш башкаруы турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү процедурасын билгеләү максатында эшләнде.

2. Муниципаль хезмәткәр, әгәр бу мәнфәгатьләр каршылыгына китермәсә һәм, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда башкасы каралмаса, яллаучы (эш бирүче) вәкиленә алдан язма рәвештә хәбәр итеп, башка түләүле эшне башкарырга хокуклы.

3. Муниципаль хезмәткәр, башка түләүле эшне башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килгән очракта, башка түләүле эшне башкаруны туктатырга тиеш.

4. Башка түләүле эшне башкаруны планлаштыручы муниципаль хезмәткәр яллаучы (эш бирүчегә) вәкиленә башка түләүле эшне башкару турында язма рәвештә хәбәр җибәрә (алга таба - хәбәрнамә) (әлеге Тәртипкә 1нче кушымта нигезендә), ул башта муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесе белән килештерелә. Күрсәтелгән хәбәрнамә башка түләүле эшне башкара башлаганчы җибәрелергә тиеш.

5. Хәбәрнамә, кергән көнне, Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан әлеге Тәртипкә 2нче кушымта формасы нигезендә алып барыла торган башка түләүле эшне башкару турында хәбәрнамәләрне теркәү журналына теркәлергә тиеш.

6. Хәбәрнамә хәбәр алынган көннән алып өч эш көне эчендә яллаучы (эш бирүчегә) вәкиленә тапшырыла.

7. Яллаучы (эш бирүче) вәкиле муниципаль хезмәткәрләрнең башка түләүле эш башкаруына каршы чыкса, хәбәрнамә бланкында ул муниципаль хезмәткәрнең башка түләүле эше мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булуы турында үз фикерен нигезли.

8. Яллаучы (эш бирүче) вәкилендә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеге турында шиге туса, муниципаль хезмәткәрнең башка түләүле эшне башкару турында хәбәрнамәсе өч көн эчендә хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиянә, хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия турындагы нигезләмә нигезендә карау өчен җибәрелә.

9. Башка түләүле эш башкару графигы, шулай ук мондый эшне башкаруга бәйле башка йөкләмәләр үзгәргән очракта, муниципаль хезмәткәр әлеге Тәртип нигезендә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итә.

Баулы муниципаль районының
җирле үзидарә органнары
муниципаль хезмәткәрләре
башка түләүле эш башкару
турында яллаучы (эш бирүче)
вәкиленә алдан хәбәр итү
тәртибенә
1нче кушымта

___________________________________
(каралу турында билге)

___________________________________________
___________________________________________
______________________
(*ФИО, эшкә яллаучы вәкиле вазыйфасы*)
___________________________________________
___________________________________________
_____________________
*(муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүченең ФИО)*

**Башка түләүле эшне башкару турында хәбәрнамә**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 11нче статьясы 2нче өлеше нигезендә, мин 20___ елның «______» ______________ түбәндәге түләүле эшне башкарырга ниятлим:
____________________________________________________________________________
*(эш төре: педагогик, фәнни, иҗади яки башка төр эш)*
____________________________________________________________________________
*(хезмәт килешүе,, граждан-хокукый килешү, авторлык килешүе һәм башкалар буенча.)*
____________________________________________________________________________
*(башка түләүле эш башкарыла торган оешманың исеме һәм әлеге оешманың адресы)*
Эш асылы
____________________________________________________________________________
*(.башкарылган эшнең характерын, мәсәлән, "студентларны укыту", "мәкаләләр язу" һ.б.)*
мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә йогынты ясамаячак.
«____» ___________ 20___ел.

____________________ ___________________
*(хәбәрнамә юллаучы зат имзасы* *(имза расшифровкасы)*

СОГЛАСОВАНО

________________________ __________________________
*(хәбәрнамәне килештергән зат вазыйфасы, ФИО)* *(имза, дата)*

Башка түләүле эш башкару турында
хәбәрнамәләрне теркәү журналында
теркәү номеры _____
Хәбәрнамәне теркәү датасы «______» ______________ 20___ ел.

___________________________ ______________________________
*(хәбәрнамәне теркәгән вәкаләтле вазыйфаи затның ФИО* *(хәбәрнамәне теркәгән вәкаләтле вазыйфаи затның имзасы*

Баулы муниципаль районының
җирле үзидарә органнары
муниципаль хезмәткәрләре
башка түләүле эш башкару
турында яллаучы (эш бирүче)
вәкиленә алдан хәбәр итү
тәртибенә
2нче кушымта

**Башка түләүле эш башкару турында хәбәрнамәләрне теркәү**
**ЖУРНАЛЫ**

| № п/п | ФИО муниципального служащего, представившего уведомление | Должность муниципального служащего, представившего уведомление | Дата регистрации уведомления | Хәбәрнамәнең кыскача эчтәлеге (эшчәнлекнең характеры), башка түләүле эш башкарылачак оешма исеме | ФИО, хәбәрнамә кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең имзасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |